Тылсымлы Сәхифәләр



# Татар халык әкиятләре

## Татарские народные сказки

## Tatar folk stories

Диск с мультфильмами в подарок!

# Өч кыз

## Три дочери ❧ The three daughters



Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер Хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу Хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, дип, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар үсеп буйга да җиткәннәр. Алар берсеннән-берсе матур, бер битләре ай, бер битләре кояш, буй-сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда Тиен дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

– Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлләремне белергә килсеннәрче, – дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан.



Жила в давние времена одна женщина. И было у неё три дочери. Много ей приходилось работать, чтобы одеть, обуть и прокормить дочерей. Вот наконец они повзрослели. И стали одна краше другой. Вышли они замуж, разъехались, и осталась мать одна.

Вот прошёл год, другой, третий. И случилось так, что мать заболела. Просит она Белку, которая жила в лесу неподалёку:

– Белка, Белка, позови ко мне моих дочерей!

Белка сразу же побежала выполнять просьбу.



Once upon a time there lived a woman. And she had three daughters. A woman had to work a lot to feed and clothe her daughters. The daughters were growing up to be good. And so they grew up to be one better than the other. And all of them got married and went away leaving the mother alone.

And so a year has passed, and another, and another. And it happened so that the mother fell sick.

She asked a squirrel that lived in the forest nearby:

– Squirrel, squirrel, call my daughters for help!

The squirrel rushed to grant the wish.



Тиен барып тәрәзә какканда, Олы кыз кер юадыр иде, ди.

– Һай, – дип әйткән, ди, Олы кыз, – бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрдәге керне юып бетерәсем бар иде шул.

Тиен моңар бик ачуланган да әйткән:

– Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! – дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар. Олы кыз егылган да шунда ук гөберле бакага әверелгән.



Прибежала Белка к старшей дочери, постучала в окно.

– Ой, – сказала старшая дочь, выслушав Белку, – я бы сразу к маме побежала, да вот бельё достирать нужно.

– Ах так, – рассердилась Белка, – тогда и не расставайся вовек со своими тазами!

Только сказала – вмиг превратилась старшая дочь в зелёную жабу.



She came to the older sister, knocked into the window.

– Oh, – said the older sister after hearing the squirrel,

– I would have helped mother, but I have bowls of washing to do.

– If so, – the squirrel became angry, – never again shall you part with your bowls!

Just as she said it, the bowls closed and the older daughter turned into a green toad.



Тиен Уртанчы кызга чапкан. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, җеп эрли икән. Тиенгә әйткән:

– Һай, әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә җеп эрләп өлгертәсем бар иде шул, – дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

– Алайса, син гомерең буе җеп эрләп кенә тор! – дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.



А Белка тем временем к средней дочери прибежала. Рассказала ей печальную весть о матери.

– Эх, побежала бы я к маме, да вот пряжу надо к ярмарке допрясть.

– Ах так, – рассердилась Белка, – тогда всю оставшуюся жизнь не расставайся со своей пряжей!

Сказала так, и средняя дочь вмиг в паука превратилась.



The squirrel meanwhile ran to the middle sister. She told her about her mother.

– Oh, I would have run to mother, but I have to finish weaving the cloth for the fair.

– If so, – the squirrel became angry, – never in your life shall you do anything but weaving!

Just as she said it the middle daughter turned into a spider.

Тиен тәрәзәсен какканда, Кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.

Тиен Кече кызга әйткән:

– И сөекле бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, – дигән.

Кече кыз, чыннан да, бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.



А когда Белка в окошко к младшей дочери постучала, та тесто месила. Как услышала она, что матери плохо, руки вытереть не успела – побежала к ней.

– Доброе у тебя сердце, – сказала Белка. – Так пусть же и люди всегда к тебе добры будут. Живи, милая, счастливо и людей делай счастливыми! И они будут любить тебя и добро твоё никогда не забудут.

Так оно и стало.





And when the squirrel knocked into the youngest sister's window, she was beting dough.

Just as she heard that mother was sick, she ran to her not even drying her hands.

– You have a good heart, – the squirrel said. – So let people always be kind to you too. My darling, live happily and make people happy! And people would love you and your kindness shall never be forgotten.

And so it was.

# Алтын бөртекләр

## Золотые зёрнышки • Golden grains



Борын-борын заманда бер ир белән бер хатын яшәгәннәр. Аларның биш уллары булган. Бердәнбер көнне боларның әтиләре Туган илне яклап, яуга киткән. Ул кире әйләнеп кайтмаган, сугыш кырында ятып калган. Ялгыз ана биш малайны үзе генә тәрбияләп үстергән.

Менә бердәнбер көнне ул улларын үз янына чакырып алган.

– Улларым, – дигән ана, – мин сезне үстердем, хәзер үз көнегезне үзегез күрегез инде.

– Без, – дигәннәр егетләр, – үз көнебезне үзебез күрер идек тә, акчабыз юк бит. Син, әни, безгә берәр генә бөртек булса да алтын бир инде.



Давным-давно жили-были муж и жена. И было у них пятеро сыновей.

Однажды отец ушёл на войну и не вернулся. Остался на поле боя. Одинокая мама растила сыновей одна.

Прошли годы.

И вот как-то раз она позвала всех сыновей к себе.

– Дети мои, – сказала мать, – я вас вырастила, а сейчас живите самостоятельно.

– Мы, – сказали юноши, – жили бы самостоятельно, да денег нет. Нам хотя бы одно золотое зёрнышко.



Once upon a time there lived a man and a wife. And they had five sons. One day the father left home for war. He left and never came back, remained lying on the battlefield. The lonely mother had to raise the family herself.

And then, one day she called all her sons.

– My boys, – the mother said, – I have raised you and now you should live on your own.

– We would have lived on our own, – the boys replied, – but we have no money. Mother, give us at least one golden grain.



– Алтын бирәм, – дигән ана, – бер бөртек түгел, мең бөртек. Тик ул алтыннарны әтиегез җыеп куйган иде. Аны үзегез эзләп табыгыз.

– Табабыз, табабыз! – дигәннәр егетләр.

– Ә-нә, – дигән ана, – Ташлытау белән Карлытауны күрәсезме? Шул ике тау арасында киң басу бар. Менә шул басуга әтиегез алтын бөртекләрен яшергән иде. Эзләп табыгыз шуны. Басуның җирен казыгыз. Иренмәгез, җиң сызганып, тир сыпырып эшләгез!

Биш егет биш сабан белән күз күреме кадәр җирне сукалап чыкканнар, аннары тырмалаганнар. Әмма бер бөртек тә алтын тапмаганнар. Шуннан егетләр, бик күңелсезләнеп, әниләре янына кайтканнар.





– Я дам вам золото, – сказала мать, – и не одно зёрнышко, а целую тысячу. Только ваш отец их собрал и спрятал. Вам нужно самим их найти.

– Найдём, найдём! – сказали братья.

– Вон там, – сказала мать, – видите горы, а за этими горами широкое поле? Вот на этом поле ваш отец и спрятал золото. Найдите его. Прокопайте землю, да не ленитесь!

Пятеро юношей взяли пять плугов и пропахали землю, а потом граблями разрыхлили почву. Но не нашли ни одного золотого зёрнышка. Сыновья очень расстроились и вернулись к матушке.



– I shall give you gold, – the mother said, – not one grain, but a thousand. Only these grains were hidden by your father. You will have to find them yourselves.

– We'll find them, we'll find them! – the boys said.

– Over there! – the mother said, – see the snowy mountain amongst the others? And between these mountains a wide field? That's the place where your father has hidden the grains. Find them. Dig up the land. Don't be lazy, work with zeal!

Five young men took five plows, tilled the soil, and then loosened it with rakes, yet didn't find a single golden grain. The sons got upset and came back to their mother.



– Бер генә бөртек тә алтын тапмадык, әни!

– Борчылмагыз, улларым, – дигән ана. – Табарсыз сез ул алтыннарны. Әнә бурадагы бодайны илтеп чәчегез шул җиргә. Көз көне, бодайны ургач, камылын йолкырсыз, бодай тамырына алтын бөртекләре эләгеп чыгар.

Егетләр әниләре әйткәнчә эшләгәннәр. Бодай мул булып уңган, аны урганнар, сукканнар.

– Китерегез миңа үзегез иккән игенне! – дигән ана.





– Матушка, мы не нашли ни одного золотого зёрнышка!

– Не расстраивайтесь, дети мои, – сказала мать, – Найдёте вы это золото! Вот возьмите зёрна пшеницы и посейте в землю. Осенью, когда взойдёт урожай, цепляясь за корни, наверх поднимутся и золотые зёрна.

Пшеница взошла, и сказала мать:

– Принесите мне выращенный вами урожай!



– Mother, we have not found a single grain!

– Don't worry, my children, – said the mother, – You will find it! Here, take some wheat corn and plant it in the land. When autumn comes the golden grains would hold to the roots and go up with the crops.

The sons did as their mother said. They cultivated the soil and planted the seeds.

– Bring me the gather harvested by you! – the mother said.



Егетләр әниләре алдына капчык-капчык игенне китереп өйгәннәр. Ана кызгылт-сары бөртекләрне учына алып караган да улларына әйткән:

– Әтиегезнең җиргә күмгән бөртекләре менә шулар инде, улларым. Сез менә аларны эзләп таптыгыз. Инде хәзер үзегез көн итә алырсыз! – дигән.

Егетләр бер-берсенә карап елмайганнар, әниләрен кочаклап алганнар. Алар әниләренең үзләрен эшкә өйрәтүен аңлаганнар.

Ә безгә, тырышлык һәм хезмәт – бәхеткә юл, дип әйтергә генә кала.





Юноши принесли и поставили перед матушкой мешки, доверху наполненные зерном. Она зачерпнула горсть пшеницы из мешка и сказала сыновьям:

– Это и есть те золотые зёрна, которые спрятал отец в поле. Вы их нашли! Теперь вы можете жить самостоятельно!

Юноши посмотрели друг на друга и счастливо заулыбались. Они поняли, что мать их научила работать.

А нам лишь остаётся сказать, что старание и труд – это путь к счастью и благополучию.



Young men placed bags filled with crops beside their mother . The mother scooped a bit of wheat from the bag and said:

– These are the golden grains that your father has hidden in the field. You have found them! Now you can live on your own!

Young men looked at each other and gave their mother a hug. They understood that mother has taught them to work.

As it is said – diligence and hard work lead to happiness!

# Төлке белән Каз

## Лиса и Гусь — The Fox and the Goose



Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:

– Каз, мин сине ашыйм! – дигән.

Каз боегып калган.

– Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит, – дигән Каз.

– Әйдә, бие, – дигән Төлке. – Ашарга өлгерермен әле.

Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган.

Төлке:

– Әй, оста биисең, Каз! – дип көлә икән. Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очкан да киткән.

Төлке авызын ачып калган.





Однажды Лиса поймала Гуся и говорит ему: «Гусь, я тебя съем».

Опечалился Гусь.

– Я согласен, Лисонька. Только разреши мне один раз поплясать напоследок, – сказал Гусь.

– Что же, давай попляши, – сказала Лиса, – Съесть тебя я ещё успею.

Гусь расправил крылья и начал притоптывать на одном месте.

– Как хорошо ты танцуешь, Гусь, – посмеивается Лиса.

А Гусь, размахивая крыльями, притоптывал, притоптывал на одном месте, а потом взмахнул посильнее крыльями да и улетел.

Лиса же осталась с открытым ртом.



Once the Fox caught the Goose and said to him:

– I am going to eat you, Goose.

The Goose saddened.

– I agree Foxy. Only let me dance for one last time, – said the Goose.

– Well, go on, dance away, – the Fox said. – I will later have a chance to eat you.

The Goose then spread his wings and started patting at one spot.

– Indeed, you are a good dancer, Goose, – the Fox laughed.

And the Goose was patting and patting at one spot swinging his wings and then he swung a little harder and flew away.

The laugh was on the Fox.

# Бүләк кемгә?

## Кому подарок? • Who is for a gift?



Бервакыт Кояш елның дүрт фасылын – Көзне, Кышны, Язны һәм Җәйне – үзенә чакырып алган.

– Сезнең кайсыгыз матуррак, кайсыгыз эштә батыррак? Шуңа бүләк бирәм, – дигән.

Ә бүләк бик затлы икән – уч тутырып йолдыз бирергә уйлаган Кояш.

Сүзне Көз башлаган:

– Үзегез яхшы беләсез, мин бөтен басуларның уңышын җыйдым, бар дөньяны алтынга күмдем. Кошларны җылы якка озаттым, балаларны мәктәпкә җыйдым. Бүләк миңа тиеш!



Как-то Солнце пригласило к себе все четыре времени года: Осень, Зиму, Весну и Лето.

– Кто из вас самый красивый, самый трудолюбивый, тому подарю подарок, – сказало Солнце.

Подарок же очень дорогой: целую горсть звёзд хотело подарить Солнце.

Первой начала говорить Осень:

– Сами знаете, я собрала весь урожай с полей, покрыла позолотой всё вокруг. Отправила в тёплые края птиц, детей собрала в школу. Подарок полагается мне.



Once the Sun summoned all four seasons: Autumn, Winter, Spring and Summer.

– Whichever one among you proves to be most beautiful and hard-working, shall receive a gift, – said the Sun. – A gift is very valuable – a handful of stars.

Autumn started first:

– You know yourselves, I've gathered all the harvest from the fields, I've covered gold around. I've sent the birds into the warm lands and chidren to schools. The gift is to be mine.



– Әллә мин эшләдемме аз? – дип, сикереп тора Яз. – Мин барлык карларны эреттем, басуларга иген чәчтем, кошларны чакырып кайтардым, агачларны яфрак ярдырдым, болыннарны чәчәккә күмдем. Арада иң матуры да, иң булдыклысы да мин! – дигән ул.

– Ай-яй, – дигән Җәй, – мине тыңлагыз әле, мин дөньяны яшеллеккә күмәм, чәчәкләр үстерәм, игеннәрне өлгертәм, җимешләрне пешерәм. Әллә мин иң матурыгыз түгелме?





Но тут вскочила Весна:

– Разве я мало работала? Я помогла растаять снегам, засеяла поля, вернула в родную сторону птиц, распустила почки на деревьях и одела их в зелёный наряд, покрыла луга цветочным ковром. И здесь я – самая красивая и самая трудолюбивая.

– Ай-ай-ай, – встрепенулось Лето, – послушайте-ка меня. Я покрываю всё кругом зелёным ковром, выращиваю цветы, помогаю созреть урожаю на полях, вызреть овощам, ягодам и фруктам. Разве не я самая красивая среди вас?



Here Spring jumped up:

– Have I not been working hard enough? I've helped the snows to melt, I've planted all the fields, I've brought the birds back to their native places, I've made shoots on trees and covered them in green dress, I've covered meadows with the flowery carpet. Therefore, I am the most beautiful and most hard-working.

– Oh, wow, wow, – shuddered Summer, – listen to me. I cover everything with green carpet, I grow flowers, help the harvest ripen on the fields, I help berries, fruits and vegetables. Am I not the most beautiful among you?



– Артык күп түгел минем эш, – ди тыйнак кына Кыш. – Мин җирне ял иттерәм, киләсе уңыш өчен карлар ташыйм, дөньяны ап-акка буйыйм, балаларны чана, чаңгы шуарга чакырам. Мин дә ямьсез түгел. Минем чыршыларымны, кар бөртекләремне, мамык бәсләремне яраталар.

Тыңлап-тыңлап торган да Кояш бүләкне берсенә дә бирә алмаган. Йолдызларны күккә сипкән. «Әнә барыгызга да!» – дигән.

Йолдызларны елның бер фасылы да үзенә ала алмаган. Алар һәрвакыт – яз да, җәй дә, көз дә, кыш та – балкып яналар.



– А у меня работы не очень много, – сказала Зима – Я даю земле отдохнуть, укрываю её снегом, чтобы вновь был хороший урожай, окрашиваю всё кругом в белый цвет, приглашаю детишек покататься на санках и коньках. Я тоже по-своему красива: все любят мои ёлочки, снежинки, иней.

Солнце послушало-послушало все времена года и решило подарок никому не давать. Рассыпало все звёзды по небу, сказав при этом: «Вот всем вам подарок».

Ни одно из времён года не смогло взять звёзды себе. Они в любое время года – и весной, и летом, и осенью, и зимой – светят всем.



– And I don't have a lot to do, – said Winter, – I give the land a chance to rest, I cover it in snow, so that the harvest would be good, I paint everything in white, I invite children to go skiing, skating and sledge-riding. I am also beautiful: everyone likes my Christmas trees, my snowflakes and my hoarfrost.

The Sun listened carefully to all the seasons and decided not to give a gift to anyone. He scattered the stars over the sky and said:

– Here is a gift to all of you!

Not one of the seasons could take the stars to herself. Be it Spring, Summer, Autumn or Winter – they shine for everyone.

# Икс кыз

## Две дочери • The two daughters



Борын-борын заманда яшәгән, ди, карт белән карчык. Аларның ике кызы булган. Олы кызлары усал да, ялкау да, саран да икән. Шуның өчен аны беркем дә яратмаган. Кече кыз үги булган. Аның уңганлыгына, аның булганлыгына кешеләр сокланып туя алмаганнар. Үги ананың моңа бик эче поша икән.

Көннәрдән бер көнне карчык иренә: «Урманга алып барып адаштыр ул кызыңны!» – дигән. Карт, ат җигеп, кызын урманга алып киткән.



В давние-давние времена жили-были старик со старухой. И было у них две дочери. Старшая дочь была злой, ленивой и жадной. Поэтому её никто не любил. Младшая же дочь – старухина падчерица – была доброй и трудолюбивой. Люди не могли нарадоваться её умениям и ловкости. Мачехе это очень не нравилось.

Вот однажды говорит старуха деду: «Отведи свою дочь в лес подальше, чтобы она там заблудилась». Запряг старик лошадь и повёз дочку в лес.



Once upon a time there lived an old man and an old woman. And they had two daughters. The older daughter was evil, lazy and greedy. That is why no one liked her. The younger daughter was a stepchild. People could not get enough of her skills and agility. The stepmother did not like it at all.

One time she told the old man:

– Go take your daughter far into the forest so that she gets lost in there. The old man put the harness on the horse and took his daughter into the forest.



Урманның иң куе җиренә барып җиткәч, ул кызына: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор, мин утын әзерлим», – дигән. Кыз җиләк җыярга керешкән.

Тырысын тутыргач, әлеге урынга килсә, әтисе юк икән. Кычкырып та караган, елап та, тик әтисе һаман күренмәгән. Ары сугылып, бире сугылып йөри торгач, бик ачыккан һәм талчыккан. Каен төбенә тамак ялгарга утырган. Бер телем ипине чыгарып ашыйм гына дигәндә, моның янына Куян, Төлке, Бүре һәм Аю килеп чыккан.



Заехав в самую чащу, он сказал: «Ты иди, собери ягод, а я пока дров нарублю». Девочка, напевая, начала собирать ягоды.

Набрав полный туесок ягод, девочка вернулась на место, но отца там уже не было. Девочка и звала его, и плакала. Походила она в одну сторону, в другую, очень устала и проголодалась. Села девочка у берёзы и достала кусочек хлеба. Тут появились Заяц, Лиса, Волк и Медведь.

After he took her far into the woods, he told the girl:

– Go collect some berries and I meanwhile will chop some trees. The girl started collecting berries singing a song.

After collecting a full basket of berries, the girl came back to the place where her father left her, but he was not there. The girl called for him, she cried, but he did not show up. She walked from one side to another; she got very tired and hungry. The girl sat down by the birch-tree and decided to eat. Suddenly right by her side appeared a rabbit, a fox, a wolf and a bear.

«Безнең ашыйсыбыз бик килә, бераз гына ипи бирче», – дип сораганнар алар.

Юмарт кыз һәрберсенә ипидән өлеш чыгарган. «Яхшылыкка – яхшылык», – дип, Куян кызга – бүрек, Төлке – тун, Бүре – читек, ә Аю бер тәпән бал китереп биргән.

Аларның китүе генә булган, кыз янына урман буенда ат көтүе көтеп йөргән Батыр килеп чыккан. Ул да кыздан ипи сораган. Ипи кисәген тәмләп кенә ашыйм дигәндә, кызның күзләренә күтәрелеп караган... һәм гомерлеккә гашыйк булган. Атына утыртып, авылга – әтисе янына алып кайткан. Һәм ярәшергә дә килгән.



«Мы очень проголодались, дай нам немного хлебушка», – сказали они.

Добрая девочка отломила каждому кусочек.

«За добро – добро», – сказали они. И подарили ей: Заяц – шапку, Лиса – шубку, Волк – сапоги, а Медведь – кадушку мёда.

Когда звери ушли, из глубины леса к ней подошёл молодой Батыр, он пас рядом табун лошадей. Он тоже попросил у девочки хлеба. А поев, посмотрел в глаза девочки, и полюбили они друг друга. Посадил он её на коня и отвёз в деревню, к её отцу. И попросил руки его дочери.

– We're very hungry, please, give us some of your bread, – they said.

The girl broke off pieces of bread for all of them. – Good for good, – said the rabbit and brought the girl a rabbit hat, the fox brought her a nice foxy coat, the wolf – a wolf coat and a bear brought her some honey.

When the animals went away into the forest a young Batyr approached the girl. He was shepherding a herd of horses nearby. He also asked the girl for some bread. And after eating it he looked into the girl's eyes and they instantly fell in love with each other. He put her onto the horse and took to the village to her father. Right at that spot he asked her father permission to marry her.



Тун кигән, янында бай кияве булган үги кызын күреп, карчык ачуыннан нишләргә дә белмәгән. «Үз кызыңны баеттың, инде минем кызымны да бает, урманга алып барып адаштыр», – дигән ул.

Карт, ат җигеп, бу кызны да урманга алып киткән. Барып җиткәч: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор, мин бераз утын әзерлим», – дигән. Кыз җиләк җыя башлаган. Бер җиләкне савытка, өчесен авызына салып йөри-йөри, тырыс төбе каплангач, әлеге урынга килсә, әтисе юк икән.

Каен төбенә ашарга утырган...



Мачеха, увидев, что падчерица и в шубах, и с женихом богатым, от злости не знает, что и делать. Говорит старику: «Ты обогатил свою дочь, теперь и мою обогати. Отвези мою дочку в лес и оставь её там».

Дед отвёз старшую дочь в лес, оставил её на том же месте и сказал: «Ты пока собери ягоды, а я дров нарублю». Стала она собирать ягоды, да только одну ягодку в кузовок, а три – в роток. Дно кузовка едва-едва покрылось ягодами. Когда же девочка вернулась на место, то отца там уже не было.

Села у берёзы поесть...



The stepmother, seeing that the stepdaughter is happy and has a rich fiance, got filled with anger. She tells the old man:

– You made your daughter rich, now do the same with mine. Take her into the forest and leave her there.

The old man took the elder daughter into the forest and left her exactly at the same place he left the younger one and said:

– You go collect some berries and I meanwhile will chop some trees. This girl, too started collecting berries, only for one berry put into the basket three were put into her mouth. The bottom of the basket got barely filled with berries. Then she came back to the place her father left her at, but he was not there.

She sat down by the birch-tree to have some food.



Әнисе җибәргән төргәкне чишүе генә булган... янында Куян, Төлке, Бүре һәм Аю пәйда булганнар.

«Безнең ашыйсыбыз бик килә, безгә бераз гына ипи бирче», – дигәннәр алар. «Китегез! Сезгә түгел, үземә дә аз әле монда!» – дигән кыз.

Җәнлекләрнең ачулары чыккан һәм аны урманнан куа киткәннәр.



И только она развернула свой узелок со снедью, рядом появились Заяц, Лиса, Волк и Медведь.

«Мы очень проголодались, дай нам немного хлебушка», – сказали они. «Уходите отсюда. Мне и самой мало», – сказала девочка. Звери разозлились и выгнали её из леса.



Just as she rolled out the bag with food her mother gave her, she was approached by a rabbit, a fox, a wolf and a bear.

– We're very hungry. Give us, please some of your bread, – they said.

– Go away! I don't even have enough for myself, – the girl said. Then she took a swing at them with the stick. The animals got very angry with the girl and chased her away from the forest.

Ә бу вакыт карчык картка әйтә икән: «Бар инде, кызым баегандыр, тизрәк өйгә алып кайт!». Карасалар, пычракка баткан кыз үзе кайтып килә икән. Карчык хурлыгыннан нишләргә дә белмәгән.

Ә үги кыз, Батырга кияүгә чыгып, бүгенгә кадәр матур тормыш кичерә, ди. Карт та алар белән бергә яши, тимерчелектә эшли, көтү көтә, ди.



А в это время старуха говорит деду: «Езжай в лес. Моя дочь, наверное, уже разбогатела. Привези скорее её домой». А дочка сама домой из леса бежит: вся грязная да чумазая. Старуха чуть не умерла со стыда. А падчерица вышла замуж за Батыра и до сих пор живёт припеваючи. Ну а старик тоже к ним переехал, на кузнице работает и табун пасти помогает.





Meanwhile the old woman told the old man:

– Go to the forest. My daughter must have already gotten rich. Take her home. But the elder daughter was already running away from the forest all dirty and grubby. The old woman was fit to die of shame. And the stepdaughter married the Batyr and still lives happily with him. The old man moved in with them. He works as a blacksmith and helps shepherding the herd.